**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Иске Чүпрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Иске Чүпрәле авылында гражданнар җыены**

# КАРАРЫ

**24 нче ноябрь 2022 ел** **Иске Чүпрәле** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы “Иске Чүпрәле авыл җирлеге " муниципаль берәмлегендә Иске Чүпрәле авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының 2019 елның 15 октябрендәге 59/3 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында»гы нигезләмә, 2022 елның 24 ноябрендә тавыш бирү йомгаклары турында, 2022 елның 24 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә, тавыш бирү тәмамланган вакытта, җыенда катнашучы 2682 кеше кертелгән, гражданнар җыенында катнашучыларның тавыш бирүдә катнашкан саны- 1397, бу исемлеккә кертелгән гражданнарның 52,09 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 1397 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде, бу гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучыларның 100% ын тәшкил итә; «Каршы» позициясе өчен, җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде, бу 0 % тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә карар иттеләр:

1. 2022 елның 24 ноябрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Чүпрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Яңа Чүпрәле авылында гражданнар җыенын 2022 елның 24 ноябрендә уздырылган, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге Иске Чүпрәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Иске Чүпрәле урамнарны яктырту челтәрен ремонтлау;

- Тынычлык, З. Нури, Яшьлек, А. Абязов ур, Культура ур. Иске Чүпрәленең Газ тыкрыгына вак таш җәю;
- З. Алимов һәм Р. Низаметдинов урамнары арасындагы юл-урам челтәрен ремонтлау;
- Иске Чүпрәледә зиратларны тоту;
- Иске Чүпрәле авылында иске агачларны кисү;
-Иске Чүпрәле авылы,Техник,Зеленая,Дементьев,З.Алимов,Тукай,Октябрьнең 50 еллыгы, Кооператив ур., Ленин ур.,урамнарына ясалма юл тигезсезлеге урнаштыру;
- Иске Чүпрәле авылының Пионерская урамындагы күперне ремонтлау» дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.
3. 2023 елда Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге Иске Чүпрәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:
- Иске Чүпрәле урамнарны яктырту челтәрен ремонтлау;
- Тынычлык, З. Нури, Яшьлек, А. Абязов ур, Культура ур. Иске Чүпрәленең Газ тыкрыгына вак таш җәю;
- З. Алимов һәм Р. Низаметдинов урамнары арасындагы юл-урам челтәрен ремонтлау;
- Иске Чүпрәледә зиратларны тоту;
- Иске Чүпрәле авылында иске агачларны кисү;
- Иске Чүпрәле авылы,Техник,Зеленая,Дементьев,З.Алимов,Тукай,Октябрьнең 50 еллыгы, Кооператив ур., Ленин ур.,урамнарына ясалма юл тигезсезлеге урнаштыру;
- Иске Чүпрәле авылының Пионерская урамындагы күперне ремонтлау.
4. Үзара салым акчаларын түләүдән азат итү:
1) 18 яшькә кадәрге дүрт яки аннан да күбрәк баласы булган гражданнар;
2) инвалид балаларның ата-аналары (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр), тулы Дәүләт тәэмин ителешендә булган балаларны исәпкә алмаганда;
3) махсус хәрби операциядә катнашучылар;
4) махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзалары(хатыны (ире), балигъ булган балалар, ата-аналар һәм эшкә сәләтсез башка затлар белән бергә яшәүчеләр);
5) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар;
6) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә (хатыны (ире), балигъ булган балалар, ата-аналар һәм эшкә сәләтсез башка затлар белән бергә яшәүче) хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаилә әгъзаларына.
5. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә кирәк: Иске Чүпрәле авылы, 2 нче бишьеллык урамы 5нче йорт, 1нче балалар бакчасы бинасында; Яшел урам № 1Б, 2нче балалар бакчасы бинасында; Иске Чүпрәле күппрофильле лицей бинасында 17-нче номерлы Газ

урамы ; Иске Чүпрәле урта мәктәбе бинасында 14 нче номерлы Үзәк урам, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы,**
**Иске Чүпрәле авыл җирлеге башлыгы урынбасары,**
**халык җыенында рәислек итүче: Р.Д.Низамов**